# Сабыр да ул, гади, кешелекле, кылган эше бары изгелек

Остазым Зайдуллина Гөлфия
Миргасыйм кызына багышлана



Остаз... Бер карасаң, гади генә, 5 хәрефтән торган бер сүз... Ә тирәнрәк уйласаң... юк, гади сүз түгел бу... Күпме тирән мәгънә, күпме аң, тырышлык, күпме кешелеккә булган мәхәббәт хисләре тупланган бу сүздә... Остаз - кеше гомеренең бизәге, маякчы, җитәкләүче, акыл һәм зиһен белән кечкенә генә кешедән Шәхес үстерүче, тәрбияләүче, шул ук вакытта аларны саклаучы, кирәк вакытта яклаучы һәм олы тормышка юл күрсәтүче, озатып калучы бөек җан ул. Бүген галим дә, табиб та, ташчы да, иген игүче дә Остазы алдында баш ия, чөнки теләсә кайсы һөнәргә юл башы аның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә салына.

Мин әлеге сүзнең мәгънәсен татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән карарга булдым. Анда: “Остаз - өйрәтүче, укытучы, җитәкче. Профессорны да "остаз" дип атау кабул ителгән. Татарча остаз сүзенең тамыры оста (мастер) сүзеннән. Элегрәк бу төшенчә балта остасын гына белдерә, соңыннан, һөнәрнең башка тармакларына да күчеп, гомумән, "мастер" мәгънәсен белдерә башлый”, дип язылган.

Дөньядагы һәрбер кеше остаз була ала микән? Мөгаен, юктыр. Бөек педагог А.С. Макаренко юкка гына “Тәрбияли белү – сәнгать ул. Скрипкада, яисә рояльдә уйный белү, матур картина тудыру сәнгате кебек сәнгать” дип әйтмәгәндер. Чөнки остаз булуга бары тик белемле, киң күңелле, сабыр, зур илаһи көчкә ия булган, һәр яктан үрнәк кешеләр генә лаектыр.

Минем остазым да бар яктан үрнәк кеше: тырыш, таләпчән, сабыр, һәр авырлыктан чыгу юлын күрсәтүче. Сүзем Зайдуллина Гөлфия Миргасыйм кызы хакында. Әйе, мин аны укытучы буларак та, директор урынбасары буларак та үземнең остазым дип саныйм. Без аның белән 1997 нче елда очраштык. Мин Лениногорск шәһәренең 11 нче гимназиясенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып килдем һәм Гөлфия Миргасыйм кызы белән бергә эшли башладым. Мин яшь, ә ул тәҗрибәле укытучы.

Шушы урында Гөлфия Миргасыйм кызының һөнәри юлы турында таныштырып китү урынлы дип уйлыйм. Зайдуллина Гөлфия Миргасыйм кызы әнисенең һөнәри эшчәнлеген дәвам итәргә теләп, 1975 нче елда Казан дәүләт педагогия институтыныың география факультетына укырга керә. Күңелле студент еллары бик тиз үтеп китә. 1980 нче елда яшь белгеч Лениногорск районы Мичурин сигезьеллык мәктәбендә педагогик эшчәнлеген башлап җибәрә. Ул география һәм биология фәннәрен укыта. Үз эшенә бирелгәнлеген, үзенә һәм укучыларына таләпчән булуын, активлыгын һәм оештыру сәләтен күреп алып, Гөлфия Миргасыймовнаны директор урынбасары, ә соңрак директор итеп билгелиләр. Ул әлеге җаваплы урында үзенең барлык сәләтен, эшлеклелеген күрсәтә. Язмыш җилләре Гөлфия Миргасыйм кызын 1989 нчы елда Лениногорск шәһәренең 11 нче гимназиясенә китерә. Ул география укытучысы буларак укучыларда тирә-як мохиткә

мәхәббәт тәрбияли, аларда кызыксынучанлык уята. Гөлфия Миргасыймовна укытуның яңа формаларын, алымнарын даими өйрәнә, аларны үз дәресләрендә уңышлы файдалана.

Укытучыга таләпләр зур. Алар замана белән бергә атларга, Һәр көн үзләренең белемемнәрен камилләштереп торырга, төрле яктан эрудицияле булырга тиеш. Борынгылар: «Кем алга бармый, шул артка тарта», – дигәннәр. Минем тормышымда очраган Гөлфия Миргасыймовна да шушы гыйбарәне истә тотып эшләүче, мине дә үзе артыннан иятүче. Ул, алган белемнәрен минем белән бүлешеп, мөстәкыйль фикер йөртә белүче, аны ачык итеп дәлилли алучы шәхес үстерү өчен бар көчен куйды. Мине яңа педагогик технологияләр өйрәнергә этәрде.

Остазымның тагы бер сүзе бүген дә минем девизым. Ул: “Таләпчәнлек. Башта үзеңнән таләп ит, соңыннан укучыдан. Бары таләпчән укытучыны гына укучылар да, әти – әниләр дә хөрмәт итәләр, югары бәялиләр. Укытучы өчен бу бик мөһим”- дип өйрәтте. Мин бүген дә аның әлеге сүзен һәрвакыт исемдә тотам, шушы сүзгә тугры булып яшим.

Остазым география укытучысы булса да, мәшһүр мәгърифәтче - галим, педагог Ризаэддин Фәхреддин сүзләрен мисалга китерә. Мине бу тагы да кызыксындыра. Ә аннары мин аның нәселе Ризаэддин Фәхреддин белән бәйле булуын белдем. Ул үзе дә: “Ризаэддин Фәхреддин нәселеннән булуым белән горурланам мин”, дия иде, ә мин аның зирәклегенә, чынлап торып зыялы булуына сокланам.

Х. Миңнегулов үзенең “Халкыбызның рухи остазы” дигән хезмәтендә Р.Фәхреддиннең бөтен яктан да белемле, укымышлы булу сәбәпләрен тикшерә. Ул аның берничә сәбәбен атый: беренчедән, татарның зыялы, рухани гаиләсеннән булуы; нәсел шәҗәрәсендә Идел-йортның билгеле кешеләре булу; икенчедән, әдипнең нәсел-нәсәбе белән бәйләнешле Бөгелмә өязе, Түбән Чыршылы, Тайсуган авыллары үзләренең мәдрәсәләре, гыйлем әһелләре белән дан тоткан.

Р.Фәхреддин үзенең әнисе ягыннан булган бабасы турында “Асар” китабының 2 томында язып калдыра. Ул аны 301 номерлы күрсәткеч белән бирә. Бабасының тулы исеме – Рәмкол бине Максуд бине Мөхсин бине Шәех. Ул аның турында түбәндәгеләрне яза: “Бөгелмә өязенең Шушма елгасының сул тарафында булган Иштирәк авылында имам булып, 63 яшендә1269 (1853) елның 15 рамазанында (10 июнь) вафат булды. Васыяте таләбенчә Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман бине чикә исемле кемсә янында күмелгән.”

И.Шиһапов аларның дәвамчылары белән кызыксына, аларның төбенә төшә, нәселләрен тикшерә. Ул болай яза:”Рәмкол балаларының икенчесе – Мостафа нәселе исә билгеле. Рәмколның улы Мостафа (башта мөәзин, аннары имам) Мостафаның улы Зәки (кибет тоткан, кибете безнең урамда таш келәт булып торды) Зәкинең олы улы Шамил, өченче улы Миргасыйм”. И. Шиһапов Миргасыйм абыйның балаларын санап чыга, тормыш иптәше Рәшидә апа турында мәгълүмат бирә. Алар белән танышканнан соң, гимназиядә география укытучысы булып эшләүче минем остазым Гөлфия апаның Миргасыйм абый кызы булуына шик калмады, фамилияләре – Мостафиннар (кыз фамилиясе, ә кияүгә чыккач ул Зайдуллина). Гөлфия Миргасыймовнаның әтисе Р.Фәхреддиннең туганнан туган энесе булып чыга. Менә бит кайда икән нәселдән килгән зирәклек, зыялылык!!!

Мин, остазым Гөлфия Миргасыймовна өйрәткәнчә, һәрвакыт үз өстемдә эшлим, күп укыйм, яңалыкка омтылам. Рәхмәт Сиңа, остазым, өйрәтүчем! Мең рәхмәт! Балалар янына керер алдыннан иң беренче Сине күз алдыма китерәм. Син бу очракта нишләр идең икән дип, үз-үземә сорау бирәм... Син һаман да миңа балаларның “Ник? Нигә? Ничек?”ләренә җавап бирергә ярдәм итәсең. Синең алда оят булмасын дип, үз-үземне алга таба үстерүгә этәрәсең, алган дәрәҗәләремнең куанычы белән уртаклашасың...

Безне тагы да якынайткан вакыйга 2001 нче елда булды: икебезне дә директор урынбасары итеп билгеләделәр. Без кулга-кул тотынышып, бергә эшли башладык. Мин тәҗрибәсез, ә ул тәҗрибәле, хәтта директор булып эшләгән кеше. Монда да остазым һәм киңәшчем булды Гөлфия Миргасыймовна. Барлык эшләрне бергә башкардык.

Менә мин укытучыларның укытучысына әйләндем. Нишләргә? Кайдан башларга? Мин гимназия үсешенә нинди өлеш кертә алам? Гимназиябезнең киләчәгенә директор урынбасары күзлегеннән карарга тиеш булдым.

Безнең гимназиянең төп максаты һәм бурычы - балаларның иҗади сәләтләрен ачу һәм үстерү өчен шартлар булдыру; аларда үзлегеннән укуга, үсешкә, ихтыяҗ тудыру; укучыларны югары белем алырга һәм төрле фәнни, практик эшчәнлек өлкәсендә иҗади эшкә әзерләү; республиканың интеллектуаль потенциалын үстерүче актив шәхес тәрбияләү.

Минем алда йөз сорау: уку-укыту планы шәхесне эстетик яктан үстерүгә нигезләнеп эшләнгәнме соң? Тагын нинди яңалык? Әлбәттә, укучыларны халык педагогикасы принципларына нигезләнеп, үз ана телендә укыту һәм тәрбия бирүгә зур игътибар итеlә. Укучыларның фән нигезләрен тирәнтен һәм күпьяклап өйрәнүенә ирешү өчен, укытуга югары уку йортлары укытучыларын җәлеп итү уңышлы булыр иде. Шушы фикерләрне тормышка ашыру ничек мөмкин соң? Уйлана торгач, гимназиядә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оештыру фикере туды. Остазым белән киңәштем, ул хуплады. Күңелне Фәнис Яруллинның сүзләре дә җилкендерде: “Тел - халык күңеленең кыңгыравы. Ә кыңгырау - кагылмасаң чыңламый. Әйдәгез, шушы кыңгырауны ешрак кагыйк. Ул тутыкмасын, тавышы гел саф, гел матур булсын, аның моңы еракка яңгырасын”. Эшчәнлегемне туган телемнең кыңгыравын кагудан башларга булдым. Кыенлыклар туды, ярдәмчеләрем остазым һәм директор булды. Шул вакытта Сократ сүзләре ярдәмгә килде: “Һәр кешедә кояш бар. Аңа яктыртырга ирек бирергә кирәк” Хезмәттәшләремнең кояшларын кабынырга мәҗбүр иткәч, оешты кафедра, фәнни җитәкче дә табылды. Минем күңел шатлана, бу идея тормышка ашты. Ышандырдым бит! Әйе, ышандырдым, башта үземне, аннары хезмәттәшләремне.

Минем карашка, директор урынбасары хезмәте кабырчык эчендәге энҗе кебек: нәтиҗә күренсен өчен башта кабырчыкны ачарга, аннан соң гына энҗе бөртеген эзләп табарга мөмкин. Кафедраның эшли башлавы энҗе бөртеге яшерелгән кабырчыкны ачуга тиң түгелмени? Әлбәттә, энҗе! Миңа иң кадерле беренче энҗемне табарга коллегам, остазым Гөлфия Миргасыйм кызы фатихасын бирде бит. Кафедра 12 укытучыны берләштерә, шуларның бишесе татар теле һәм әдәбияты укытучысы, дүртесе башлангыч класс укытучылары, өчесе өстәмә белем бирү педагоглары. Кафедра бүгенге көндә “Яңа коммуникатив технологиядәр кулланып, белем сыйфатын күтәрү, укучыларның иҗади сәләтен үстерү ” дигән методик тема өстендә эшли.

Бүгенге көндә кафедраның беренче бурычы - укучыларның тормышка яраклашуын (социальләшүен) тәэмин итүче чара буларак дәүләт телләрен һәм чит телләрне сыйфатлы өйрәтү. Президентыбыз тарафыннан республиканың мәгариф системасы алдына үз фикерләрен телдән дә, язмача да дөрес һәм матур итеп әйтә ала торган шәхесләр әзерләү бурычы куелган иде.

Моны хәл итү өчен ни эшләргә соң? Минем алда сораулар, сораулар... Яткан таш хәлендә калмас өчен нишләргә? Әлбәттә, минуты саен үзгәреп торган бу дөньяда замана сулышын эләктереп калырга! Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, башкача булмый! Укучылар югары технологияләрне иярләгән дәвердә дәреслеккә, гади тактага, акбурга гына ябышып яту һич мөмкин түгел. Актив педагогик эзләнү! Үстерелешле укыту технологиясе принцибына нигезләнгән билгеле бер методик система! Бөек мәгърифәтче Р.Фәхреддиннең: ”Күп белдерүгә караганда аз белдереп, эзләнү орлыгын салу, эзләгәнен үзе табарга өйрәтү, юлларын күрсәтү - мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр” - дигән сүзләре бүген дә актуаль булып кала.

Алда куелган максат һәм бурычларны үтәү өчен, гимназиядә фәннәрне яңа технологияләр аша өйрәтәбез. Ул - укучыларның актив эшчәнлегенә этәргеч бирү. Цицерон юкка гына “Белемле булу гына җитми, аны куллана белергә дә кирәк”, димәгәндер. Соңгы елларда гимназиянең укыту процессында кулланылучы технологияләр булып үстерелешле укыту технологиясе, компьютер технологияләре, проектлар

технологиясе, уен технологиясе, коммуникатив технология, А.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе, әдәбиятны укытуда А. Яхин методикасы, Сингапур методикасы структуралары тора. Әлеге юнәлеш белән мин җитәкчелек итәм, алай гына да түгел хәзер үзем юл күрсәтәм. Ә мине бу юлга остазым Гөлфия Миргасыйм кызы кертеп җибәргән иде.

Лаеклы ялга чыкканчы Гөлфия Миргасыймовна гимназиядә укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшләде. Аның эшләгән һәр эше кешеләрне сөендерә. Ул ачык йөзле, ярдәмчел, таләпчән җитәкче. Аңа кеше хәленә керә белү, ярдәм итү, үз тәҗрибәсе аша киңәш бирү кебек сыйфатлар хас. Шагыйрь әйткәнчә, сабыр да ул, гади, кешелекле, кылган эше бары изгелек.

Директор урынбасарының эшчәнлеге энҗе төймә кебек, төсләре, формалары, зурлыклары буенча аерым бөртекләрдән тора. Бер җыюда гына төймә уңышлы чыкмаска да мөмкин. Аны кабат-кабат сүтеп җыярга да туры килә. Минем эшчәнлек тә нәкъ шундый. Минем янәшәмдә эшләүче укытучыларым – бу гади генә укытучы түгел, ул омтылучан, таләпчән, үз эшенең остасы, татар халкының горурлыгы булырлык күпкырлы шәхес. Аның өчен педагогик камиллеккә омтылу, иртәгәсе көн белән яшәү, үз укучыларының мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен биш бармагы кебек белеп, аларны киләчәк тормышка әзерләү хас. Шундый укытучылар белән горурланып, үземә бетмәс көч алып эшлим. Үз өлешемне дә күрәм. Шушы вакытта минем уңышларым өчен сөенеп торучы кеше барлыгын да беләм, ул- минем остазым, әлбәттә.

Уйлар, уйлар... Минем алдымда үзем ачкан энҗе бөртекләреннән тезелгән төймә ята. Аның энҗеләре күпме? Аларны кабырчык эченнән чыгару һәм тезү өчен күпме көч сарыф ителгән? Ничек кенә булса да, алар минекеләр... Минем хезмәтем дә шушы энҗеләрне табу, камилләштерү, тезүдән гыйбарәт. Фәкать эзләнергә, яңалыкка омтылырга, билгеләнгән максатка кыю барырга гына кирәк. Янында маякчы, җитәкләүче, шәхес үстерүче һәм тәрбияләүче, кирәк вакытта яклаучы һәм юл күрсәтүче остазың булуы да бик кирәк. Хезмәт юлымда минем өчен иң югары бәя ул – Татарстан Республикасының атказанган укытучысы исеменә лаек булу. Минем бу уңышымда Зайдуллина Гөлфия Миргасыйм кызының да өлеше бар. Тормыш юлымда Гөлфия Миргасыйм кызы кебек кеше очравы, минем очен чиксез зур бәхет! Язмамның азагында остазыма зур рәхмәтемне һәм чиксез хөрмәтемне белдерәсем килә.

Сәмигуллина Венера Минсәгыйть кызы,
югары квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы.